ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 гыйнвар 2024 ел № 279

Яр Чаллы шәһәре территориясендә гадәттән тыш хәл янаганда һәм килеп чыкканда эвакуацияләнүче (күчерелүче) зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары булдыру һәм аларның эшен оештыру турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр янау һәм килеп чыгу зонасына эләгүче Яр Чаллы шәһәре халкын вакытлыча күчерү (урнаштыру) буенча чараларны планлаштыру, тәэмин итү һәм үткәрү буенча бурычларны хәл итү, медицина ярдәме күрсәтү, җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм саклау максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре территориясендә гадәттән тыш хәл янаганда һәм килеп чыкканда эвакуацияләнүче (күчерелүче) зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәре территориясендә гадәттән тыш хәл янаганда һәм килеп чыкканда эвакуацияләнүче (күчерелүче) зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары исемлеген, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Вакытлыча урнаштыру пунктларын үз вакытында оештыру һәм әзерләүне контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәренең эвакуация комиссиясенә йөкләргә.

3. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы янаган яки килеп чыккан очракта халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары исемлеген раслау турында» 2018 елның 23 октябрендәге 6289 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе мөдире Р.К. Шипеевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 19 гыйнварындагы
279 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә гадәттән тыш хәл
янаганда һәм килеп чыкканда эвакуацияләнүче (күчерелүче) зыян күргән
халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә гадәттән тыш хәл янаганда һәм килеп чыкканда эвакуацияләнүче (күчерелүче) зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары турында әлеге нигезләмә (алга таба – нигезләмә) «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, гадәттән тыш хәлләрдә беренче чиратта халык яшәешен тәэмин итүне һәм зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларының эшен оештыру буенча Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының гамәлдәге методик рекомендацияләре нигезендә эшләнгән һәм Яр Чаллы шәһәре территориясендә гадәттән тыш хәл (алга таба – ГТХ) янаганда һәм килеп чыкканда эвакуацияләнүче (күчерелүче) зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларының төп бурычларын, аларны оештыру һәм эшләү тәртибен билгели.

2. ГТХда зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пункты (алга таба – ВУП) ул – беренче чиратта халык яшәешен тәэмин итү (БЧХЯТИ), мәҗбүри күчеп килүчеләр (качаклар) һәм ГТХ зонасыннан эвакуацияләнә торган затлар өчен билгеләнгән техник һәм материаль чаралар, җиһазлар һәм эшләнмәләр комплексы. Зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасының шәһәр звеносы элементы булып тора. ВУП гадәттән тыш хәл яки ГТХ янау зонасыннан күчерелгән (эвакуацияләнгән) халыкны кабул итү, вакытлыча урнаштыру, исәпкә алу һәм беренче чиратта аның яшәешен тәэмин өчен булдырыла.

3. Зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын әзерләү көндәлек эшчәнлек режимында алдан үткәрелә.

4. Яр Чаллы шәһәре территориясендә ГТХ куркынычы янаган яки килеп чыккан очракта халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларының эшчәнлеге Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәренең норматив хокукый актлары һәм әлеге нигезләмә белән билгеләнә.

2 бүлек. ВУПның максаты һәм бурычлары

5. ВУПны булдыруның төп максаты булып ГТХ янаганда яки килеп чыкканда оештыру ягыннан иң катлаулы чорда кешеләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклау өчен тиешле шартлар тудыру һәм аларны үтәү тора.

6. ВУПның төп бурычлары булып тора:

1) көндәлек эшчәнлек режимында: ГТХ ихтималы булу зонасыннан чыгарыла торган халыкны оешкан төстә кабул итү буенча чаралар планлаштыру һәм аларны гамәлгә

ашыруга әзерләнү; кирәкле документларны эшләү; биналарны, инвентарьны, саклау чараларын (медицина битлекләрен, инфракызыл термометрларны, дезинфекцияләү чараларын) һәм элемтә чараларын алдан әзерләү; ВУП администрациясен ГТХда зыян күргән халыкны кабул итү, исәпкә алу эшләренә әзерләү; өйрәнүләр һәм тренировкалар барышында ВУП администрациясенә хәбәр итү, җыю һәм эшләтү мәсьәләләрен практик яктан эшләп карау; эвакуация чараларын оештыру буенча эшләнә торган планнарның реальлеген тикшерү һәм практик күнекмәләр алу максатыннан Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе – Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы бурычларын һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бурычларын хәл итү өчен махсус вәкаләтләнгән орган, Яр Чаллы шәһәренең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе (алга таба – ГТХ һәм ЯКТИК) тарафыннан үткәрелә торган өйрәнүләрдә, тренировкаларда һәм тикшерүләрдә катнашу;

2) гадәттән тыш хәл режимында: ВУПны тулысынча эшләтү; кешеләрне кабул итәргә һәм урнаштырырга әзерләнү; килә торган халыкны исәпкә алуны оештыру һәм урнаштыру; Яр Чаллы шәһәренең бердәм дежур диспетчерлык хезмәте, эвакуацияләнә торган халыкның яшәешен тәэмин итүдә катнаша торган оешмалар белән элемтә урнаштыру; эвакуацияләнә торган халыкның беренче чиратта яшәешен тәэмин итүне оештыру, зыян күргән халыкның ВУПка килүе турында мәгълүмат бирү, Яр Чаллы шәһәренең эвакуация комиссиясенә, ГТХ һәм ЯКТИКка халыкны кабул итү һәм урнаштыру барышы турында хәбәрләр, докладлар җибәрү; зыян күргән халыкны озак яшәү пунктларына җибәрергә әзерләү (торгызу эшләре озак дәвам иткәндә).

### 3 бүлек. ВУП администрациясенең тәкъдим ителә торган составы

7. ВУП администрациясенең штаты ГТХда зыян күргән кабул ителүче халык саныннан тора һәм эвакуацияләнә (күчерелә) торган халыкны оешкан рәвештә кабул итүне планлаштыру, оештыру һәм урнаштыру, шулай ук беренче чиратта халык яшәешен тәэмин итүнең барлык төрләре белән тәэмин итү өчен булдырыла.

8. ВУП администрациясе штатына керә:

| | |
|---|---|
| Җитәкчелек: | |
| ВУП башлыгы | - 1 кеше |
| ВУП башлыгы урынбасары | - 1 кеше |
| Кабул итү, теркәү һәм исәпкә алу төркеме: | |
| төркем башлыгы | - 1 кеше |
| регистратор-исәпкә алучы | - 2 кеше |
| Халыкны урнаштыру төркеме: | |
| төркем башлыгы | - 1 кеше |
| исәпкә алучы | - 2 кеше |
| Җәмәгать тәртибен саклау төркеме: | |
| төркем башлыгы | - 1 кеше |
| дружиначы | - 2 кеше |
| Белешмәләр өстәле: | |
| белешмәләр өстәле дежурные | - 2 кеше |
| Ана һәм бала бүлмәсе: | |
| дежурный (балалар бакчаларының урта яки кече персоналы арасыннан, мәктәп хезмәткәрләре) | - 2 кеше |
| Медицина пункты: | |
| пункт башлыгы | - 1 кеше |
| урта (кече) персонал | - 2 кеше |

Психолок ярдәм пункты:

психолог - 2 кеше

Сәүдә һәм туклану пункты:

сәүдә һәм туклану пункты башлыгы - 1 кеше

повар - 3 кеше

9. ВУПның шәхси составы үзенең функциональ бурычларын белергә һәм намус белән үтәргә тиеш.

10. ВУП администрациясенең шәхси составын әзерләү Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә, Россия ГТХМның оештыру-методик күрсәтмәләрен исәпкә алып, шулай ук гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча өйрәнүләрдә һәм тренировкаларда катнашып алып барыла.

## 4 бүлек. ВУП эшен оештыру

11. Базасында зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пункты ачыла торган оешманың җитәкчесе ВУП эшләү өчен кирәк булган документларны эшләүне, материаль-техник тәэмин итүне, ВУП администрациясен практик укытуны оештыра һәм ВУПның зыян күргән халыкны кабул итәргә әзер булуы өчен персональ җаваплы була.

12. ВУП эшен регламентлаучы төп документ булып әлеге нигезләмә тора. ВУП администрациясе үз эшчәнлегендә Яр Чаллы шәһәре ГТХ һәм ЯКТИКка буйсына, ә Яр Чаллы шәһәре эвакуация комиссиясе эвакуация чаралары башкарганда халыкның беренче чиратта яшәешен тәэмин итүдә катнаша торган оешмалар белән үзара эшчәнлек алып бара.

13. ВУП ачу боерыгы (күрсәтмәсе) алынуга ВУП администрациясенең календарь эш планы нигезендә чаралар башкарыла.

14. Эвакуацияләнә торган халыкны урнаштыру аның базасында зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пункты ачыла торган оешма биналарында, аның материаль-техник чараларыннан һәм җиһазларыннан файдаланып планлаштырыла һәм гамәлгә ашырыла. Кирәк булган очракта объект эшчәнлеге Башкарма комитет җитәкчесе карары буенча туктатыла.

15. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гражданнар оборонасының сәүдә һәм туклану хезмәте тарафыннан ачыла торган туклану пунктын урнаштыру һәм ачу өчен мөмкинлектән чыгып гамәлдәге ашханә һәм ярдәмче биналар бирелә.

16. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гражданнар оборонасының медицина хезмәте тарафыннан ачыла торган медицина пунктын һәм психологик тәэмин итү бүлмәсен урнаштыру өчен ВУП башлыгы үз карамагы буенча аерым биналарны алдан күздә тота.

17. Эвакуацияләнә торган халыкның яшәешен тәэмин итү буенча барлык мәсьәләләрне ВУП башлыгы Яр Чаллы шәһәре ГТХ һәм ЯКТИК һәм Яр Чаллы шәһәре эвакуация комиссиясе белән берлектә хәл итә.

18. Җирле үзидарә органнары һәм оешмалар тарафыннан халыкны вакытлыча урнаштыру буенча үткәрелгән чараларга, шул исәптән материаль-техник, азык-төлек, медицина запасларын һәм башка чараларны файдалануга тотылган чыгымнар Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә каплана.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2024 елның 19 гыйнварындагы
279 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә
гадәттән тыш хәл янаганда һәм килеп чыкканда эвакуацияләнүче
(күчерелүче) зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары
исемлеге

| № т/б | Вакытлыча урнаштыру пунктлары оештырыла торган оешмаларның исеме | Адрес |
|---|---|---|
| 1 категория (барлык ел фасылларында яшәү мөмкинлеге бар, 3 тапкыр туклану, яшәеш тулаем тәэмин ителгән) | | |
| 1. | «Отель Опен Сити» ҖЧҖ (килешү буенча) | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 2 йорт |
| 2. | «КАМАЗжилбыт» ҖЧҖ «КАМАЗ» кунакханәсе (килешү буенча) | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Яңа шәһәр, Академик Рубаненко урамы, 12 (1/16) йорт |
| 3. | Яр Чаллы шәһәренең «Жемчужина» санаторие профсоюзлар учреждениесе (килешү буенча) | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Мәләкәс уамы, 1 йорт |
| 3 категория (ГТХ булган очракта мәгариф объектлары (мәктәпләр, югары уку йортлары һ.б.) һәм мәдәни-массакүләм объектлар (мәдәният йортлары һ.б.) базасында ачыла торган ВУП) | | |
| 4. | «9 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Александр Грин исемендәге урам, 8/2 йорт |
| 5. | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 44 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Бумажники бульвары, 3 (17а\18) йорт |
| 6. | «22 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Солнечный бульвары, 2 йорт |
| 7. | «41 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Илдар Маннанов исемендәге урам, 11 йорт |
| 8. | «27 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Мир проспекты, 94 йорт |

| | | |
|---|---|---|
| 9. | Яр Чаллы шәһәренең «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 34 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Ш. Усманов урамы, 110 йорт |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева